**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

**КАРАР**
**утыз өченче утырыш**

**02 июль 2024 ел** **№ 250** **Теләче авылы**

Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 4 апрелендәге 199 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 341 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 4 апрелендәге 199 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган (26.05.2014 № 210, 15.11.2016 № 67, 20.04.2017 № 84, 19.07.2017 № 90, 12.04.2018 № 127, 24.08.2018 № 141, 13.12.2018 № 160, 20.01.2020 № 224, 30.07.2020 № 246, 03.09.2020 № 248, 30.06.2021 № 63, 01.02.2023 № 171, 20.10.2023 № 210, 28.12.2023 № 229, 07.03.2024 № 233 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең (алга таба - Нигезләмә) 32.1 статьясының 10 өлешенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурста Россия Федерациясе дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм уку тәмамланганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган уку яисә башка шартнамә буенча бурычлары булмаган гражданнар катнашырга хокуклы.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ ГОМУМИ БҮЛЕГЕ